ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2017 Казан ш. № 7-9/т

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын бер урыннан икенче урынга күчерү һәм саклау өчен тарифларның база дәрәҗәсен билгеләү турында

Федераль тарифлар хезмәтенең "Тоткарланган транспорт чараларын бер урыннан икенче урынга күчерү һәм саклау өчен тарифлар хисаплау һәм түләү чорлары билгеләү буенча методик күрсәткечләр раслау турында" 2016 елның 15 августындагы 1145/16 боерыгы нигезендә, тоткарланган транспорт чараларын бер урыннан икенче урынга күчерү һәм саклау өчен тарифлар билгеләү максатында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын бер урыннан икенче урынга күчерү һәм саклау өчен тарифларның база дәрәҗәсен билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 22.12.2017 № 7-9/т карарына кушымта

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын бер урыннан икенче урынга күчерү һәм саклау өчен тарифларның база дәрәҗәсе

| № п/п | Эшләр һәм хезмәтләр аталышы | Тарифларның база дәрәҗәсе, сум | |
|---|---|---|---|
| | | (НДС башка) | (НДС белән) |
| 1. | Тоткарланган транспорт чарасын махсус машина кую урынына күчерү, бер транспорт чарасын күчергән өчен, шул исәптән: | 1 925,42 | 2 272,0 |
| 1.1. | төяү-бушату эшләре | 561,02 | 662,0 |
| 2. | Тоткарланган транспорт чарасын махсус машина кую урынында саклау, бер сәгатькә бер урын өчен, шул исәптән: | | |
| 2.1. | A, A1, M, B1 категориясендәге | 22,23 | 26,23 |
| 2.2. | B, D1, C1 категориясендәге | 44,46 | 52,46 |
| 2.3. | C, D, BE, C1E, D1E категориясендәге | 88,92 | 104,93 |
| 2.4. | CE, DE категориясендәге | 111,19 | 131,20 |
| 2.5. | габаритлы булмаган транспорт чаралары | 133,38 | 157,39 |

Искәрмә:

Төяү-бушату эшләре өчен түләү транспорт чарасын тоткарлау сәбәпләре юкка чыгарылганнан соң аны махсус транспорт чарасына төягәч һәм махсус машина кую урынына саклау өчен урнаштырганчыга кадәр алына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге